ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары турындагы мәгълүматын тыңлап һәм аның буенча фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары һәм ирешелгән нәтиҗәләр турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Дәүләт органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мәгълүмат технологияләреннән файдалану, ведомствоара электрон документлар әйләнеше механизмын камилләштерү һәм ведомство мәгълүмат ресурсларын башка белешмәләр чыганаклары белән синхронлаштыру юлы белән алга таба арттыруны тәэмин итүне.

2.2. Цифрлы икътисадны үстерү өчен шартлар булдыру буенча өстенлекле юнәлешләрнең берсе буларак закон чыгару барышын цифрлаштыруга ярдәм күрсәтүне.

2.3. Кабул ителә торган идарә итү карарлары сыйфатын арттыруны, шул исәптән дәүләт программалары нәтиҗәлелегенә анализ ясау өчен ясалма интеллект һәм «зур мәгълүмат» системасын кертү юлы белән, тәэмин итүне.

2.4. Дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне цифрлы трансформация нигезләренә укыту буенча гамәлгә ашырыла торган программаларның эчтәлеген киңәйтүне.

3. Дәүләт идарәсе өлкәсендә цифрлы технологияләрне үстерү һәм мәгълүмат системаларын эшләүгә һәм аларга ярдәм күрсәтүгә чыгымнарны оптимальләштерү, шулай ук аларның мәгълүмат иминлеген тәэмин итү

максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:

3.1. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарында файдаланыла торган мәгълүмат системаларын «Татарстан Республикасы Цифрлы хезмәт күрсәтүләр» дәүләт мәгълүмат системасы белән интеграцияләүне тәэмин итәргә.

3.2. Барлык дәүләт хезмәт күрсәтүләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт күрсәтүләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр» гамәли платформасына күчерү эшен оештырырга.

3.3. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларның гамәли эшчәнлегенә закон чыгару барышына ярдәм күрсәтү буенча автоматлаштырылган системаларны кертү эшен оештырырга.

3.4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәмммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1872-VI ДС